**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның 18 июленнән № 58-448

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 14 декабрендәге 39-321 номерлы карары белән расланган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына хуҗа булырга һәм (яисә) файдалануга тапшырылырга тәгаенләнгән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милкендәге күчемсез муниципаль мөлкәт исемлегенә өстәмәләр кертү турында

Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм оешмаларга, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 14 декабрендәге 39-321 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2024 елның 13 декабрендәге 50-391 номерлы, 2025 елның 17 апрелендәге 53-412 номерлы карарлары редакциясендә) расланган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына хуҗа булырга һәм (яисә) файдалануга тапшырылырга тәгаенләнгән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милкендәге күчемсез муниципаль мөлкәт исемлегенә (алга таба - Исемлек) түбәндәге эчтәлектәге 72 пункт өстәргә:

| № т/б | Милек атамасы | Милекнең урнашу урыны | Мәйданы (кв. м.) | Кадастр номеры |
|---|---|---|---|---|
| 72 | Торак булмаган бина (склад) | ТР, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Парк ур. 12 й. | 225,4 | 16:31:150106:132 |

2. Әлеге карарны вакытлы матбугат басмасы - «Яңа Чишмә хәбәрләре» («Шешминская новь») газетасында https://novoshishminsk.ru,«Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының

рәсми порталы» нда https//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары Н.И. Попкова